| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» 02 2021 ел № 75

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2008 елның 23 маендагы 197 номерлы карары белән расланган «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан күпфатирлы йортларның гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт өчен субсидияләр бирү турында» (2020 елның 16 октябрендәге 302 номерлы үзгәрешләр белән) нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәүнең көтелгән нәтиҗәләре һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең уртак коллегиясенең 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы Беркетмәсенең 24, 25 пунктларын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2008 елның 23 маендагы 197 номерлы карары белән расланган «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан күпфатирлы йортларның гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт өчен субсидияләр бирү турында» (2020 елның 16 октябрендәге 302 номерлы үзгәрешләр белән) Нигезләмәнең 2.1 пунктындагы 2 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 5 абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау.».

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов